**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-34-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 78 от 12 март 2018 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы “Югары Кәминкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы Федераль законның 44 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 85, 86, 87 статьялары нигезендә, "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы карары белән 2013 нче елның 18 нче июлендә №54 (07.04.2014 ел №62, 07.05.2015 ел №89, 22.01.2016 ел №18, 15.12.2016 ел №39, 01.06.2017 ел №52 кертелгән үзгәрешләр белән) кабул ителгән "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5 нче статья:

а) 1 нче өлештә:

а) 9 нчы пунктны түбәндәге басмада бәян итәргә: “авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен

контрольдә тоту, әлеге пунктларга ярашлы рәвештә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру”;

б) 14 нче пунктны түбәндәге басмада бәян итәргә: “каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән, аерым җыю) һәм башка җиргә күчерү эшчәнлеген оештыруда катнашу”.

1.2. 6 нчы статья:

- 1 нче пунктның 10 нчы подпунктын көчен югалткан дип санарга.

1.3. 10 нче статья:

15 нче пунктны түбәндәге басмада бәян итәргә: “Җәмәгать тыңлаулары”;

15 нче пунктны 16 нчы пункт итеп санарга

1.4. 19 нчы статья:

- 19 нчы статьяның исемен түбәндәге басмада бәян итәргә: “19 нчы статья. Халык тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышу”;

- 1 нче өлештә “җәмәгать тыңлаулары үткәрелергә мөмкин” сүзтезмәсен “яки иҗтимагый фикер алышу” белән тулыландырырга;

- 3 нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге 3.1. подпункты белән тулыландырырга: “3.1. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектлар, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш объектларының чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектлары, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалану рөхсәт ителгән бер төрне үзгәртү мәсьәләләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда, мондый куллануның башка төре җәмәгать тикшерүләре яисә халык тыңлаулары үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезләмәләрне исәпкә алып, җирлек Советы Уставы һәм норматив хокукый акты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә;

- 3 нче өлешнең 4 нче подпунктын яңа басмада бәян итәргә: “4) авыл җирлеген үзгәртеп коруга “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлек халкының тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында ризалыгы таләп ителгән очраклардан тыш үзгәртеп кору мәсьәләләре дә кала”.

1.5. “Халык җыены” исемле 22 нче статьяны яңа басмада бәян итәргә:

“1. Халык җыены җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы формасы булып тора.

2. Халык җыены “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы закон белән каралган очракларда һәм “Җирлек Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына кергән торак пунктларда гражданнар җыеннарын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында”гы положение нигезендә үткәрелә.

3. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 статьясы нигезендә халык җыены түбәндәгечә үтә ала:

1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертә торган торак пунктта;

2) авыл җирлеге составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелә ала.

4. Гражданнар җыены җирлек башлыгы тарафыннан яисә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше булган торак пункт халкы төркеме инициативасы белән чакырыла ала.

5. Җыен үткәрү инициативасына ярдәм итәргә тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, даими яки нигездә торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санынңан 5 процент тәшкил итә, ләкин 25тән дә ким булырга тиеш түгел.

6. Җирлек башлыгы тарафыннан тәкъдим ителә торган гражданнар җыены җирлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан күрсәтелә торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләргә халык җыеннарын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итәләр, “Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенә керә торган торак пунктларда җыеннарны әзерләү тәртибе турында" гы Карарда билгеләнгән тәртип нигезендә халык җыенында күтәреләчәк сораулар буенча муниципаль хокукый акт проекты һәм материаллар белән гражданнар алдан ук таныша.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлар регистрына кертелергә тиеш”.

1.6. 33 нче статьяның 1 нче өлешендә:

- 5-6 пункты үз көчен югалткан дип санарга;

- түбәндәге эчтәлектәге 5.1. пункты белән тулыландырырга: “җирлекнең стратегик планлаштыру документларын карау, раслау (хуплау)”;

- 26 нчы пунктны түбәндәге басмада бәян итәргә: “җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау”;

1.7. 38 нче статьяны яңа басмада бәян итәргә:

“38 нче статья. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Җирлек Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла ала:

1) әгәр җирлек Советы үз-үзен таркату турында карар кабул иткән очракта. Шул ук вакытта үз-үзен таркату турындагы карар әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә кабул ителә;

2) җирлек Советы депутатларының әлеге составының хокуксыз булуы турында Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергән очракта, шул исәптән депутатлар үз вәкаләтләреннән баш тарткан очракта;

3) №131-ФЗ санлы Федераль законның 13 статьясының 3,5 нче өлешләре нигезендә җирлекне үзгәртеп корган очракта, шулай ук җирлек бетерелгән очракта;

4) җирлек чикләрен үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка килгән сайлаучылар саны 25 проценттан арткан очракта;

5) гражданнарның турыдан-туры белдерүләре юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару вакыты бозылган очракта;

2. Җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Халык сайланган депутатлардан торган җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлек Советына вакытыннан алда сайлаулар законда билгеләнгән срокларда үткәрелә.

1.8. 40 нче статьяны:

- түбәндәге эчтәлектәге 1.2. пункты белән тулыландырырга: “1.2. Җирлек Башлыгын вазыйфадан читләштерү турында Татарстан Республикасы Президенты хокукый акты нигезендә йә Җирлек Советының отставкага җибәрү турындагы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Җирлек Башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга суд тәртибендә шикаять бирсә, муниципаль сайлауларда сайланучы Җирлек Башлыгын вакытыннан алда сайлау суд карары үз көченә кергәнче билгеләнә алмый”.

1.9. 40 нче статьяда:

а) 1 нче өлештә 2 нче абзацны алып ташларга;

б) 1 нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга: “- җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә, җирлекнең Россия Федерациясе һәм татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килешенгән Озак вакытка исәпләнгән максатларын һәм бурычларын билгели, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнарын һәм программаларын үтәүне оештыра;

- Җирлек вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын әзерли, карый, раслый (хуплый) һәм тормышка ашыра;

- Җирлек Советы тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- 1 нче өлешнең 1 подпунктының 7 нче абзацында “законнарда билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” дигән сүзләр белән алмаштырырга;

в) 2 нче пунктта 13 нче абзацта “федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру” сүзләрен алып ташларга;

г) 4 нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге подпункт белән тулыландырырга: “каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнаша”4

д) 6 нчы өлешне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга: “җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота, күрсәтелгән кагыйдәләр белән тәңгәллектә төзекләндерүне оештыра”.

1.10. 63 нче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 3 нче өлеш белән тулыландырырга:

“3. “Муниципаль вазыйфа биләгән затка карата коррупциячел хокук бозулар кылган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендәге түләтү турында белешмәләр бу зат анда тиешле вазыйфа биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә”.

1.11. Түбәндәге эчтәлектәге 69.1 статьясы белән тулыландырырга:

**“69.1 нче статья. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен тоту.**

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре Җирлек Советы тарафыннан раслана.

2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә ала:

1) гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү һәм мондый территорияләрдән файдалану тәртибе;

2) бинаның, корылмалар тышкы кыяфәте һәм киртәләү конструкцияләре;

3) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу, шул исәптән җир эшләрен үткәргәннән соң;

4) җирлек территориясен яктыртуны оештыру, шул исәптән биналар, корылмалар архитектур яктыртуны да кертеп;

5) муниципаль берәмлек территориясен яшелләндерүне оештыру, торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннар, чәчәк түтәлләре һәм үлән үсемлекләре белән биләнгән башка территорияләрне төзү, карап тоту, торгызу һәм саклау тәртибен дә кертеп;

6) җирлек территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йортларның номерлары, элмә такталары куелган күрсәткечләр урнаштыру;

7) балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыклар, парковкалар (парковка урыннары), кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту;

8) җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны, аллеяләрне, юлларны, сукмакларны оештыру;

9) инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре күрсәтелгән территория буенча тоткарлыксыз хәрәкәт итүне тәэмин итү максатларында җирлек территориясен төзекләндерү;

10) авыл җирлеге территориясен, шул исәптән кышкы чорда җыештыру;

11) яңгыр суларын агаып төшүне оештыру;

12) җир эшләрен үткәрү тәртибе;

13) бина, корылма, җир кишәрлекләренең милекчеләренең һәм (яки) башка законлы хуҗаларының якын-тирә территорияләрне карап тотуда катнашуы (мондый йортларның чикләре буенча төзелмәгән яки төзелгән җир участокларында урнашкан күпфатирлы йортларда мәйдан биләп торучы милекчеләр һәм (яки) башка законлы хуҗаларыннан тыш);

14) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртип нигезендә якын-тирә территорияләрнең чикләрен билгеләү;

15) авыл җирлеге территориясендә бәйрәм бизәлеше;

16) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда гражданнарның һәм оешмаларның катнашу тәртибе;

17) җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны тормышка ашыру.

1.12. 78 нче статьяның 7 нче пунктының 4 нче абзацын үз көчен югалткан диеп санарга;

1.13. 80 нче статьяны яңа басмада бәян итәргә:

“80 нче статья. Гражданнарның үзсалым акчасы.

1. Гражданнарның үзсалым акчалары дигәндә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салым түләүләре күләме муниципаль берәмлекнең барлык халкы өчен дә тигез күләмдә билгеләнә, аларның саны муниципаль берәмлек халкының гомуми санынннан 30 процентган артып китә алмый һәм алар өчен түләү күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш.

2. Әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән гражданнар бер тапкыр түләргә тиешле түләүләрне кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә җирле референдумда (гражданнар җыенында), ә 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1 статьясының 1 нче өлешенең 4 һәм 4.1 пункларында каралган очракларда – халык җыенында хәл ителә.

1.14. 87 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 4,5 пунктлары белән тулыландырырга:

“Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү муниципаль хокукый акт тарафыннан кертелә, аны түбәндәгечә рәсмиләштереп була:

- Җирлек Советы (гражданнар җыены) рәисе һәм Җирлек Башлыгы имзалаган, яисә Җирлек Советы (гражданнар җыены) рәисе вәкаләтләрен башкаручы Җирлек Башлыгы имзалаган Җирлек Советы (гражданнар җыены) карары нигезендә;

- Җирлек Советы (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм Җирлек Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт нигезендә. Бу очракта әлеге хокукый актта Җирлек Советының (гражданнар җыенының) аны кабул итү турындагы карары реквизитлары куела. Җирлек Советының (гражданнар җыенының) мондый карарына күчеш нигеләмәләре һәм (яисә) Җирлек Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турындагы нормалар кертү рөхсәт ителми.

5. Җирлек Уставын федераль законга һәм Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законда һәм Татарстан Республикасы законында әлеге срок куелмаган очракта, Җирлек Уставын федераль законга һәм Татарстан Республикасы законына туры китерү тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы Законы үз көченә керү датасын, Җирлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектын халык тыңлауларында рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) һәм фикер алышу кирәклеген, гражданнарның аның буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу, Җирлек Советы утырышларының вакытлылыгы, мондый муниципаль хокукый актның дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, гадәттә, 6 айдан да артмаска тиеш”.

2. Әлеге карарның 1.1. пунктының “б” подпункты, 1.9. пунктының “г” подпункты дәүләт теркәвенә алынганнан соң үз көченә керә, ләкин 2019 нчы елның 1 нче гыйнварыннан да иртәрәк түгел дип билгеләргә.

3. Түбәндәге карарны законлылык белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органының территориаль органына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны, дәүләт теркәвеннән соң, мәгълүмати стендларда урнаштырырга, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 статьясының 8 нче өлешендә каралган нигезләмәләргә, "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 87 нче статьясының 2 нче өлешенә нигезләнеп аны рәсми игълан иткән көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Башлыгы К.М.Гилязов